КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 11 ноябрь г.Казань № 1457

2023 елда «Туристлык инфраструктурасын үстерү» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында Алабуга шәһәренең туристлык үзәген төзекләндерү чараларын үткәрү өчен кирәкле мәдәни мирас объектларын саклап калу буенча фәнни-проект документациясен эшләү һәм дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасын узу өлешендә җирле үзидарә органнарының муниципаль район милкендәге мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру буенча вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2023 елда «Туристлык инфраструктурасын үстерү» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында Алабуга шәһәренең туристлык үзәген төзекләндерү чараларын үткәрү өчен кирәкле мәдәни мирас объектларын

саклап калу буенча фәнни-проект документациясен эшләү һәм дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасын узу өлешендә җирле үзидарә органнарының муниципаль район милкендәге мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру буенча вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 14 ноябрь, 1457 нче
карары белән расланды

2023 елда «Туристлык инфраструктурасын үстерү» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында Алабуга шәһәренең туристлык үзәген төзекләндерү чараларын үткәрү өчен кирәкле мәдәни мирас объектларын саклап калу буенча фәнни-проект документациясен эшләү һәм дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасын узу өлешендә җирле үзидарә органнарының муниципаль район милкендәге мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру буенча вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип 2023 елда «Туристлык инфраструктурасын үстерү» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында Алабуга шәһәренең туристлык үзәген төзекләндерү чараларын үткәрү өчен кирәкле мәдәни мирас объектларын саклап калу буенча фәнни-проект документациясен эшләү һәм дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасын узу өлешендә җирле үзидарә органнарының муниципаль берәмлек милкендәге мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру буенча вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы (алга таба – муниципаль берәмлек) бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар (алга таба – башка бюджетара трансфертлар) бирү механизмын билгели.

2. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты).

3. Башка бюджетара трансфертлар әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен 2023 елга Дәүләт комитетына җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

4. Финанслашу чыганагы башка бюджетара трансфертлар булган чыгымнарның юнәлеше – «Туристлык инфраструктурасын үстерү» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында Алабуга шәһәренең туристлык үзәген төзекләндерү чараларын үткәрү өчен кирәкле мәдәни мирас объектларын саклап калу буенча фәнни-проект документациясен эшләү һәм дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасын узу.

5. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары:

муниципаль берәмлекнең тормышка ашыру өчен башка бюджетара трансфертлар бирү гамәлгә ашырыла торган Алабуга шәһәренең туристлык үзәген төзекләндерү чаралары исемлеген раслый торган хокукый акты булу;

әлеге Тәртипнең 6 пункты нигезендә башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзү;

муниципаль берәмлек бюджетында (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет исемлегендә) «Туристлык инфраструктурасын үстерү» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында Алабуга шәһәренең туристлык үзәген төзекләндерү чараларын үткәрү өчен кирәкле мәдәни мирас объектларын саклап калу буенча фәнни-проект документациясен эшләү һәм дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасын узу буенча муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен бюджет ассигнованиеләре булу.

6. Муниципаль берәмлек бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү Дәүләт комитеты тарафыннан башка бюджетара трансфертлар бирү турында карар кабул ителгән вакыттан алып 15 көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә Дәүләт комитеты һәм муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты арасында төзелә торган Килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

7. Башка бюджетара трансфертларны алу өчен муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты, билгеләнгән тәртиптә таныкланган түбәндәге документларны теркәп, Дәүләт комитетына башка бюджетара трансфертлар бирү турында ирекле рәвештә язылган заявка (алга таба – заявка) тапшыра:

муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына муниципаль берәмлек бюджеты (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет исемлеге) турында кабул ителгән карарыннан вәкаләтле зат тарафыннан таныкланган һәм муниципаль берәмлек бюджетында (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет исемлегендә) «Туристлык инфраструктурасын үстерү» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында Алабуга шәһәренең туристлык үзәген төзекләндерү чараларын үткәрү өчен кирәкле мәдәни мирас объектларын саклап калу буенча фәнни-проект документациясен эшләү һәм дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасын узу буенча муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бирергә планлаштырыла торган башка бюджетара трансфертлар күләмен үз эченә алган бюджет ассигнованиеләре булуын раслый торган өземтә;

әлеге Тәртипнең 5 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән муниципаль хокукый акт күчермәсе.

8. Муниципаль берәмлекнең башкарма комитетыннан кергән документлар Дәүләт комитеты тарафыннан алар теркәүгә алынган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 15 көн эчендә карап тикшерелә. Документлар Дәүләт комитеты тарафыннан кергән көнендә теркәүгә алына.

Әлеге Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмаган (тулы күләмдә тапшырмаган) яисә тапшырылган документлар, алардагы белешмәләр әлеге Тәртиптә каралган шартларга туры килмәгән очракта, шулай ук муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты тарафыннан тапшырылган мәгълүмат дөрес булмаган очракта, Дәүләт комитеты гаризаны кире кага һәм гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән биш көннән дә соңга калмыйча, кире кагуның сәбәпләрен күрсәтеп, муниципаль берәмлекнең башкарма комитетына мөрәҗәгать итә.

Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты, әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләрне үтәү шарты белән, заявканы кире кагу турында хәбәрнамә алган көннән

10 көн эчендә яңадан заявка бирергә хокуклы.

Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты тарафыннан яңадан бирелгән заявкаларны карап тикшерү тәртибе беренче тапкыр бирелгән заявкаларны карап тикшерү тәртибе белән охшаш.

Башка бюджетара трансфертлар бирү турында карар муниципаль берәмлекнең башкарма комитетыннан кергән документларны карау тәмамланганнан соң 3 көн эчендә Дәүләт комитеты тарафыннан кабул ителә.

9. Башка бюджетара трансфертлар Дәүләт комитеты белән муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты арасында Килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә муниципаль берәмлекнең финанс органына ачылган муниципаль берәмлек бюджетының бердәм счетына муниципаль берәмлек бюджетына Дәүләт комитеты тарафыннан күчерелә.

10. Башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткече нигезендә гамәлгә ашырыла.

11. Башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе – «Туристлык инфраструктурасын үстерү» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында Алабуга шәһәренең туристлык үзәген төзекләндерү чараларын үткәрү өчен кирәкле мәдәни мирас объектларын саклап калу буенча фәнни-проект документациясенең 1 (бер) комплектын эшләү һәм дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасын узу.

12. Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты Дәүләт комитетына электрон төрдә һәм кәгазьдә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган формалар буенча, Килешүдә каралган срокларда өстәмә финанслау максаты белән башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгымнар турында хисап, башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсенең мәгънәсенә ирешү һәм аңа ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында хисап кертергә тиеш.

13. Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты һәм аның вазыйфаи затлары тапшырыла торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертларның максатчан файдаланылмавы өчен законнар нигезендә җавап бирә.

14. Әгәр муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты тарафыннан 2023 елның 31 декабренә карата Килешүдә каралган йөкләмәләр бозылган булса, 2024 елның беренче 15 эш көне эчендә муниципаль берәмлек бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акча күләме ($V_{\text{кире кайтару}}$) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$V_{\text{кире кайтару}} = (C_i \times D) \times 0{,}1,$$

монда:

$C_i$ – хисап финанс елында муниципаль берәмлек бюджетына бирелгән башка бюджетара трансферт күләме;

D – башка бюджетара трансфертны кире кайтару коэффициенты.

16. Башка бюджетара трансфертны (D) кире кайтару коэффициенты түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$D = 1 - \frac{T}{S},$$

монда:

T – хисап датасына башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенең фактта ирешелгән зурлыгы;

S – Килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенең план буенча мәгънәсе.

16. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланылмаган һәм (яки) муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты тарафыннан аны бирү шартлары бозылган, шул исәптән муниципаль берәмлек тарафыннан бу Тәртипнең 14 пункты нигезендә акча Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылмаган очракта, аңа карата Россия Федерациясенең бюджет законнарында каралган мәҗбүр итүнең бюджет чаралары кулланыла.

17. 2024 елның 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар 2024 елның беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемено күчерелмәгән очракта, әлеге акча, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты керемено түләтелергә тиеш.

18. Башка бюджетара трансфертлар максатчан характерга ия һәм бүтән максатларда (әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлардан башка) кулланыла алмый.

19. Башка бюджетара трансфертларны максатчан файдалануны контрольдә тоту Дәүләт комитеты һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

______________________________